**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге составына керүче Әтнә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында КАРАР (РЕШЕНИЕ)**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 1 ноябрендә «Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Әтнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр кешегә, (I төркем инвалидларга, үз-үзләренә хезмәт күрсәтә алмый торган гражданнарга, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ялгыз ата-аналарга (законлы вәкилләргә, Россия Армиясе сафларында вакытлы һәм контрактлы хезмәте үтүче егетләргә үзара салым суммасының 90 проценты күләмендә ташлама каралган) Комсомол, کече, Искандаров урамнары буенча юл ремонтлау өчен 500 сум күләмендә салым кертергә килешәсезме" – дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында, сайлау хокукына ия булган, җыенда катнашучылар исемлегенә кертелгән - 202 кеше, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 119 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен җыенда 119 кеше тавыш бирде;

"Юк" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Әтнә авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре чын дип танырга.

2. «Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Әтнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр кешегә, (I төркем инвалидларга, үз-үзләренә хезмәт күрсәтә алмый торган гражданнарга, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ялгыз ата-аналарга (законлы вәкилләргә, Россия Армиясе сафларында вакытлы һәм контрактлы

хезмәте үтүче егетләргә үзара салым суммасының 90 проценты күләмендә ташлама каралган) Заря урамы буенча юл ремонтлау өчен 500 сум күләмендә салым кертергә килешәсезме" – дигән сорауны гамәлдә дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә дә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Заляев